| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2022 елның 7 ноябре № 28

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм авыл җирлеге территориясенең тиешле санитар торышын тәэмин итү, авыл җирлеге территориясен пычратудан саклау чараларын тормышка ашыру максатыннан, Зеленая Роща авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 142 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«142. Умарталарны тоту өчен урыннар (алга таба - умарталыклар) түбәндәге ераклыкта булырга тиеш:

Торак пунктларда яки гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләрендә (алга таба - бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре) очу юлын әлеге участоклар чикләреннән капма каршы якка юнәлдереп күршедәге җир кишәрлекләре чикләреннән кимендә 3 метр ераклыкта яки умарталыкларны башка җир кишәрлекләреннән 2 метрдан ким булмаган койма белән аерып алу шарты булганда очу юлын ераклык һәм юнәлеше буенча чикләүләрсез»;

б) 134 пунктта «башка зат» сүзләреннән соң «,яисә терлекләрне көтү өчен билгеләнгән территориядә терлекләрне тоту җайланмасын кулланып» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур., 1 йорт, Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасы, Спиридоновка авылы, Совет урамы, 32 нче йорт Спиридоновка авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

ИНН 1625000729
КПП 164901001

А.А.Потапов